КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 октябрь г.Казань № 912

Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы фондын төзү турында

«Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүне гамәлгә ашыручы һәм банкрот дип танылган йорт салучыларның йөкләмәләрен өлешле төзелештә катнашучылар алдында җайга салу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Фонд оештыру-хокукый формасында коммерциячел булмаган унитар оешма – Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы фондын (алга таба – Фонд) булдырырга.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына:

төзелә торган Фондны Татарстан Республикасы исеменнән гамәлгә куючы буларак чыгыш ясарга;

әлеге карар үз көченә кергәннән соң 10 көн эчендә Фонд уставын билгеләнгән тәртиптә эшләргә һәм расларга;

Фондны дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә һәм аны булдыру буенча Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда башка юридик әһәмияткә ия гамәлләр башкарырга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Фондны төзегәндә гамәлгә куючы 2019 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 30,0 мең сум күләмендә мөлкәти кертем кертә;

Фонд эшчәнлеге планы, керемнәрнең һәм чыгымнарның финанс планы (бюджеты), шул исәптән чираттагы финанс елына административ-хуҗалык чыгымнары сметасы, Фондның штат расписаниесе, Фонд хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фонды күләме Фондның иң югары коллегиаль идарәсе органы тарафыннан раслана.

4. Күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын төзү эшләре гражданнар акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган, фондның техник заказчысы функцияләре – өлешләп төзүдә катнашучыларны «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә һәм (яисә) инженер-техник инфраструктура, социаль инфраструктура объектларын, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын, гомуми белем бирү оешмаларын, поликлиникаларны, транспорт инфраструктурасы объектларын һәм капиталь төзелеш объектларын төзү эшләрен тәгәлләү, төзелеш объектларын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруны (технологик тоташтыруны) тәэмин итүче оешмалар «Татарстан Республикасының Баш инвестицион-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан гамәлгә ашырыла, ул Фонд тарафыннан аның кушуы буенча һәм аның исеменнән шартнамә нигезендә техник заказчы функцияләрен гамәлгә ашыру вәкаләте бирелә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин